МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

31.12.2020 г.Казань № 1011

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 1 февралендә 7532 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы белән расланган Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 31.07.2015 №533, 06.06.2016 №316, 28.11.2016 №668, 29.03.2017 №194, 08.06.2017 №349, 22.12.2017 №895, 07.05.2018 №351, 18.09.2018 №885, 02.04.2019 №221, 03.09.2019 №666, 14.11.2019 №1012, 06.02.2020 №71, 01.06.2020 №380 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының 2020
елның 31 декабрендәге 1011 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы белән расланган Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.4 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән барлык кирәкле документлар (ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча рәсми мөрәҗәгать җибәрү зарурлыгы булмаган очракта) гариза теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә кабул ителә.

Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар соратып алу зарурлыгы булганда, дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты барлык кирәкле документлар белән гаризаны теркәгәннән соң ун эш көненә кадәр озайтыла.

Гражданнарның керемнәре турында белешмәләргә өстәмә тикшерү үткәрелгән очракта, балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар әлеге тикшерүдән соң, әмма барлык кирәкле документлар белән гариза теркәлгәннән соң 30 календарь көненнән дә соңга калмыйча, кабул ителә.

Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү бурычларны түләүгә кадәр туктатыла, ләкин дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көннән дә артыгракка түгел.

Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

2.5 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2.6 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша алына:

гаилә әгъзаларында күчемсез милек барлыгы турында белешмәләр (Росреестрда);

билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урыны турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);

гаилә әгъзаларында транспорт чаралары булуы турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда);

балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда);

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында яисә ата-ана хокукында чикләнү турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

яшәү (вакытлыча тору) урыны буенча мөрәҗәгать итүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда);

уналты яшьтән өлкәнрәк балага (балаларга) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында белем алуы турында белешмәләр (гомуми белем бирү оешмасыннан);

опека (попечительлек) билгеләү, баланы тәрбиягә алган гаиләгә тапшыру турында, баланы карап тоту өчен опекун (попечитель) ала торган акча күләме һәм тәрбиягә бала алган ата-аналарга тиешле түләү суммалары турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);

физик зат файдасына эшкә яллаучы (иминиятләштерүче) тарафыннан түләнгән түләүләрнең яки башка төрле бүләкләүләрнең суммасы турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

социаль түләү күләме турында белешмәләр:

Россия Эчке эшләр министрлыгыннан түләнә торган пенсияләр (Россия Эчке эшләр министрлыгында);

Россия Оборона министрлыгыннан түләнә торган пенсияләр (Россия Оборона министрлыгында);

Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан башкарыла торган пенсияләр, компенсация түләүләре, пенсионерларны өстәмә айлык матди тәэмин итү (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

эшсезлек буенча пособиеләр (халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләрендә);

эшсез гражданнарга матди ярдәм һәм башка түләүләр күләме (халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләрендә);

һөнәри белем алган һәм мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган чорда гражданнарга түләнә торган стипендия һәм матди ярдәм (халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләрендә);

җәмәгать эшләрендә катнаша торган эшсез гражданнарга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ булган эшсез гражданнарга вакытлыча эшләрдә катнашкан чорында түләнә торган түләүләр (халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләрендә);

вакытлыча эшләрдә катнашкан чорында 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарга түләнә торган түләүләр (халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт учреждениеләрендә);

вакытлыча эшкә яраксызлык буенча пособиеләр (Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органнарында);

эштәге бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча ай саен түләнә торган иминият түләүләре(Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органында);

йөклелек һәм бала табу буенча пособиеләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органнарында);

йөклелекнең иртә срокларында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган пособие (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органнарында);

яшь ярымлык яшенә җиткәнче бала карау буенча ай саен түләнә торган пособие (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органнарында);

I төркем инвалидны, дәвалау учреждениесе бәяләмәсе буенча даими рәвештә чит кешеләр тәрбиясенә мохтаҗ яки 80 яшенә җиткән өлкән кешене карый торган, эшкә сәләтле эшләми торган затларга айлык компенсация (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

18 яше тулмаган инвалид баланы яки балачактан ук I төркем инвалидны карый торган эшкә сәләтле эшләми торган затларга айлык түләү (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

чакыру буенча хәрби хезмәт үтә торган хәрби хезмәткәрнең баласына айлык пособие (социаль яклау органында);

мәктәпкәчә белем бирү оешмасында баланы караштырган һәм караган өчен компенсация (социаль яклау органында);

читләр каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) даими рәвештә мохтаҗ 18 яше тулмаган инвалид балаларга айлык акчалата түләү (социаль яклау органнарында);

берьюлы туган өч һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә яшь ярымга кадәр ай саен түләнә торган пособие (социаль яклау органнарында);

гражданнарга торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә субсидия (шул исәптән субсидия-ташламалар) (социаль яклау органнарында);

торак урынга һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә гражданнарның аерым категорияләренә түләнә торган компенсация (социаль яклау органнарында);

беренче бала туу (уллыкка алу) белән бәйле рәвештә, айлык түләү (социаль яклау органнарында);

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булуы турында (вәкаләтле оешмаларда).

Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша мөрәҗәгать иткән очракта, өстәмә рәвештә ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча мөрәҗәгать итүченең паспортының чынлыгын раслау турында мәгълүмат алына (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгында).

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон

формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Үзәк мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны»;

2.8 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булуы дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып тора.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

2.5 пунктта күрсәтелгән документларның тапшырылмавы, 2.5 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының 3 пунктында күрсәтелгән, бердәнбер ата-анага карата документлардан тыш, аның кереме булмаган очракта яки ата-аналарның берсенә карата, әгәр аның керемнәре булмаса һәм ата-ананың икенчесе хезмәт эшчәнлеген башкарса яисә пенсионер булып торса яки инвалид бала караучы зат булса (яки I төркем инвалид яки дәвалау учреждениесе бәяләмәсе буенча даими рәвештә ятлар каравына мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге яки 80 яшенә җиткән зат булса) яисә 18 яшенә кадәр биш һәм аннан күбрәк баласы булган, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган булса;

әгәр бала (балалар) тулысынча дәүләт тәэминатында булса, Россия Федерациясе гражданнарының, чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның мөрәҗәгать итүе;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән яисә ата-ана хокуклары чикләнгән Россия Федерациясе гражданнарының, чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның мөрәҗәгать итүе;

әгәр бала опекада (попечительлектә) торса һәм опекун (попечитель) аны карап тоту өчен акча алса;

әгәр 18 яшькә кадәрге бала өйләнешү аркасында яки аның эмансипациясе белән бәйле рәвештә, эшкә хокук алган булса;

әгәр балага пособие сорап мөрәҗәгать иткән ата-анага карата алимент йөкләмәләре барлыкка килгән булса;

мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары балага айлык пособие билгеләү турында сорап мөрәҗәгать иткән көннән соң 90 көн эчендә җайга салынмаган булса;

мөрәҗәгать итүче гаиләсенең мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсенең «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән артып китүе;

2.14 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктының икенче абзацында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-ноктала

хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, 15 статьясы»;

3 бүлектә:

3.1.1 пунктчаның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар әзерләү;»;

3.4.1 пункттагы өченче абзацында «- Татарстан Республикасы территориясендә туу актын теркәү очрагында, « сүзләрен төшереп калдырырга;

3.4.2. пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Балага пособие билгеләү турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында – вәкаләтле органга;

Россия Федерациясе Пенсия фондына – хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында яисә ата-ана хокукында чикләнү турында, җирле үзидарә органнарына;

опека (попечительлек) билгеләү, баланы тәрбиягә алган гаиләгә тапшыру турында, баланы карап тоту өчен опекун (попечитель) ала торган акча күләме һәм тәрбиягә бала алган ата-аналарга тиешле түләү суммалары турында – җирле үзидарә органнарына;

вәкаләтле оешмаларга – балага айлык пособие билгеләү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган физик затларның керемнәре турында;

Россия Оборона министрлыгыннан түләнә торган пенсия күләме турында – Россия Оборона министрлыгына;

социаль яклау органнары яисә Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органнары тарафыннан йөклелек һәм бала табу буенча түләнә торган пособие күләме турында – социаль яклау органнарына яисә Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органнарына;

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органнары яисә Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органнары тарафыннан йөклелекнең иртә срокларында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга түләнә торган, бер тапкыр бирелә торган пособие күләме турында – социаль яклау органнарына яисә Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органнарына;

социаль яклау органнары яисә Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органнары тарафыннан яшь ярым тулганчы бала караган өчен түләнә торган айлык пособие күләме турында – социаль яклау органнарына яисә Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органнарына;

вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособие күләме турында – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнына;

физик зат файдасына эшкә яллаучы (иминиятләштерүче) зат тарафыннан түләнгән түләүләрнең яки башка төрле бүләкләүләрнең суммасы турында – вәкаләтле органга;

Россия ЭЭМ тарафыннан түләнә торган пенсия күләме турында – Россия Эчке эшләр министрлыгына.

эштәге бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча ай саен түләнә торган иминият түләүләре күләме турында – Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органына;

беренче бала туу (уллыкка алу) белән бәйле рәвештә, социаль яклау органына – айлык түләү күләме турында;

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнә торган, I төркем инвалидны караучы, дәвалау учреждениесе бәяләмәсе буенча даими рәвештә чит кеше каравына мохтаҗ өлкән яисә 80 яшькә җиткән карт кешене караучы, эшләми торган эшкә сәләтле затка түләнә торган айлык компенсация түләүләренең, 18 яшенә кадәрге инвалид баланы яки балачактан I төркем инвалид булган баланы караучы, эшләми торган эшкә сәләтле затка түләнә торган айлык түләүләр күләме турында – Россия Федерациясе Пенсия фондына;

яшәү (вакытлыча тору) урыны буенча мөрәҗәгать итүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында – вәкаләтле органгв;

уналты яшьтән өлкәнрәк балага (балаларга) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында белем алуы турында – гомуми белем бирү оешмаларына;

гаилә әгъзаларында күчемсез милек барлыгы турында – Росреестрга;

билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урыны турында – җирле үзидарә органнарына;

гаилә әгъзаларында транспорт чаралары булуы турында – вәкаләтле органнарга;

гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелгән булса, мөрәҗәгать итүченең паспортының чын булуын раслау турында – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булуы (булмавы) турында – вәкаләтле органга.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать.»;

3.5-3.6 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар әзерләү

3.5.1. Үзәк бүлеге белгече әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән, алынган белешмәләр һәм әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда алынган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле буларак катнашучы затның яисә алар тарафыннан вәкаләт бирелгән затның вәкаләтләрен тикшерә;

әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булу-булмавын тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен кирәкле, әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентка 3 нче һәм 6 нчы кушымталар нигезендәге формалар буенча электрон рәвештә бала өчен пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яисә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проектын рәсмиләштерә;

балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проектын электрон рәвештә Үзәк бүлеге җитәкчесенә имза кую өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган көннән ике эш көне эчендә, әмма гаризаны теркәгәннән соң җиде эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яки электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар проекты.

3.5.2. Үзәкнең бүлек җитәкчесе балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар проектын карый һәм электрон санлы имза белән имзалап, Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын имзалау җибәргәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм Үзәк бүлеге белгеченә җибәрелгән балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар.

3.5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында белдерү

Үзәкнең бүлек белгече дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан балага пособие билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карарга кул куйганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

3.5.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту яки балага пособие билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү

3.5.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү туктатып торылган вакыт эчендә мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавы турында белешмәләре алынса яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән бурычны җайга салуны раслый торган документлар тапшырылган очракта, Үзәк бүлеге белгече:

әлеге Регламентка 6 нчы кушымта нигезендәге форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту турында карар проектын электрон рәвештә рәсмиләштерә;

әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендә балага пособие билгеләү турында карар проектын рәсмиләштерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту һәм балага пособие билгеләү турындагы карар проектларын Үзәкнең бүлек җитәкчесенә имзалу өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычның булмавы яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан бурычларны җайга салуны раслый торган документлар тапшырылганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне яңадан торгызу һәм элемтә хезмәтләре күрсәтүгә субсидия билгеләү турында карарлар проектлары.

3.5.4.2. Мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычларны җайга салмаган очракта, балага пособие билгеләү турында гариза биргән көннән соң 90 көн узгач, Үзәкнең бүлек белгече балага пособие билгеләүдән баш тарту турында карар проектын әзерли һәм Үзәк

җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура балага пособие билгеләү турында гариза биргән көннән соң 90 көн узгач, аннан соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: балага пособие билгеләүдән баш тарту турында карар проекты.

3.5.4.3. Үзәк бүлеге җитәкчесе дәүләт хезмәте күрсәтүне яңадан торгызу турында һәм балага пособие билгеләү турында карар проектларын яисә балага пособие билгеләүдән баш тарту турында карар проектын карый һәм электрон санлы имза белән имзалый һәм Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне яңадан торгызу турында һәм балага пособие билгеләү турындагы карар проектларына яисә балага пособие билгеләүдән баш тарту турындагы карар проектына кул куйганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан имзаланган дәүләт хезмәте күрсәтүне яңадан торгызу һәм балага пособие билгеләү яки балага пособие билгеләүдән баш тарту турында карарлар.

3.5.4.4. Үзәкнең бүлек белгече дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан балага пособие билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту турында карарга кул куйганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

3.6. мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Үзәкнең бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына юллау юлы белән) балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар җиткерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар җибәрү.»;

3.8 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Техник хатаны төзәтү әлеге Регламентка 5 нче кушымтаге форма буенча, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турындагы документны яки мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник

хатасы булган документны (әгәр андый документлар бирелгән булса) теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза тапшырылган очракта гамәлгә ашырыла.»;

3.8.1 пунктта:

өченче абзацта «үзгәртеп рәсмиләштерә» сүзләреннән алда «дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар проектын яки» сүзләрен өстәргә.

дүртенче абзацта «үзгәртеп рәсмиләштерелгән» сүзләреннән соң «дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар проекты яки» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацта «үзгәртеп рәсмиләштерелгән» сүзләреннән соң «дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар проекты яки» сүзләрен өстәргә;

3.8.2 пунктта:

беренче абзацта «үзгәртеп рәсмиләштерелгән» сүзләреннән соң «дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар яки» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «үзгәртеп рәсмиләштерелгән» сүзләреннән соң «дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар яки» сүзләрен өстәргә;

3.8.3 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.3. Үзәк бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына юллау юлы белән) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар яки балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итә.»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар яки балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итү, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны яки балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына юллау.».

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №_ бүлегенә

___________________________________________

(муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА №______

____________ 20__ ел.

Мин

______________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яисә законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта) тулысынча)

| Шәхесне раслаучы документ исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

яши торган адрес:

______________________________________________________________________,
(индексын күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең почта адресы, телефоны, электрон почта адресы)
эш итү нигезе:

______________________________________________________________________ ,
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эш итүен раслый торган документларның реквизитлары, ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)
Мөрәҗәгать итүченең хосусый шәхси счет номеры ____________________________
Билгеләвегезне сорыйм ____________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча)
яши торган адрес: ____________________________________________________________

______________________________________________________________________________
(почта индексы, мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлү адресы)

______________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ реквизитлары)
Балага айлык пособие

______________________________________________________________________________
(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча)
Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының милегендә булган мөлкәт турында белешмәләр <*>:

1. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле, мәйданы гаиләнең һәр әгъзасына исәпләгәндә 40 квадрат метрдан артып китә торган торак урын (торак урынның бер өлеше),

бар юк

шул исәптән:

1.1. Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән, законнар нигезендә бергә яшәү мөмкинлеген бирми торган хроник авыруның катлаулы формасыннан интегүче гаилә әгъзасы яшәгән торак урын (шул исәптән фатирда изоляцияләнгән аерым торак урын мәйданы) мәйданы;

бар юк

Мәйда-нын күрсә-тергә

1.2. билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урын;

бар юк

2. гомуми мәйданы ялгыз яшәүче гражданинга исәпләгәндә 40 квадрат метрдан артып китә торган, ә ике һәм аннан күбрәк кешедән торган гаиләгә гаиләнең һәр әгъзасына 23 квадрат метрдан артып китә торган, Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле ике һәм аннан күбрәк торак урыннары (торак урыннарының өлешләре),

бар юк

шул исәптән:

2.1. Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән, законнар нигезендә бергә яшәү мөмкинлеген бирми торган хроник авыруның катлаулы формасыннан интегүче гаилә әгъзасы яшәгән торак урын (шул исәптән фатирда изоляцияләнгән аерым торак урын мәйданы) мәйданы;

бар юк

Мәйда-нын күрсә-тергә

2.2. билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урын;

бар юк

| | | |
|---|---|---|
| 3. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле һәм торак урын булып тормаган (транспорт чараларын (гараж, машина урыны), хуҗалык корылмалары урнаштыру өчен билгеләнгән, хосусый торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрендә, бакча җир кишәрекләрендә урнашкан күчемсез милек объектларыннан тыш, шулай ук әлеге кушымтаның 4 пунктында саналган объектлардан тыш) биналар, төзелмәләр, корылмалар (бинаның, төзелмәнең, корылманың өлешләре); | бар | юк |
| 4. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле, хуҗалык корылмалары булмаган, гаиләнең бер әгъзасына исәпләгәндә гомуми мәйданы 40 квадрат метрдан артып китә торган бер яки берничә бакча йорты, дача (бакча) төзелеше объектлары; | ☐ бар | ☐ юк |
| 5. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле, гомуми мәйданы (суммар мәйданы) гаиләнең бер әгъзасына исәпләгәндә 0,2 гектардан артып китә торган бер яки берничә җир кишәрлеге; | ☐ бар | ☐ юк |
| 6. Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән автомобиль, автобус, үзйөрешле машина, пневматик һәм чылбырлы механизм, самолет, вертолет, теплоход, яхта, җилкәнле судно, катер, снегоход, моточана, гидроцикл, тарттырыла торган үзйөрешле булмаган судно, суда һәм һавада йөри торган башка төрле чара (утыру өчен биштән артык урыны булган һәм дүрт һәм аннан күбрәк балалы күпбалалы гаиләләр тарафыннан алынган (сатып алынган) җиңел автомобильдән тыш); | ☐ бар | ☐ юк |
| 7. мөрәҗәгать итү көненә чыгарылган елы өчтән артмаган ике һәм аннан күбрәк җиңел автомобиль (инвалид тарафыннан файдалану өчен махсус җиһазландырылган җиңел автомобильдән тыш, утыру өчен биштән артык урыны булган һәм дүрт һәм аннан күбрәк балалы күпбалалы гаиләләр тарафыннан алынган (сатып алынган) җиңел автомобильдән тыш). | ☐ бар | ☐ юк |

--------------------------------

<*> мөлкәтнең булуы «V» билгесе белән билгеләнә; мөлкәтнең булмавы «X» билгесе белән билгеләнә.

Түләү алучы затның гаилә составы:

| | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (туган көне) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Паспорт (туу турында таныклык) реквизитлары | Кирәклесен билгеләргә <**> |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

--------------------------------

<**> дәүләт хезмәте билгеләнә торган балалар билгеләнә.

Гаризада күрсәтелгән балаларның (баланың) тулысынча дәүләт тәэминатында булмавын раслыйм, шулай ук аларга (аңа) карата

______________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителмәгән, ата-ана хокукында чикләнмәгән

__________ ______________________________

(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең имзасы, тулы имзасы)

______________________________________________________________

(балага опека билгеләнгәндә опека билгеләгән органның исемен һәм урнашу урынын күрсәтергә)

Уналты яшьтән өлкәнрәк бала (балалар) белем ала:

______________________________________________________________

(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме) (гомуми белем бирү оешмасы атамасы)

______________________________________________________________

(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме) (гомуми белем бирү оешмасы атамасы)

Билгеләнгән түләүләрне күчерергә:

счет реквизитлары ______________________________________________

(банкта яки башка кредит учреждениесендә законда билгеләнгән тәртиптә мөрәҗәгать итүче яисә аның законлы вәкиле тарафыннан ачылган шәхси счет реквизитлары күрсәтелә)

почта бүлеге реквизитлары ______________________________________

(мөрәҗәгать итүченең яки законлы вәкилнең почта реквизитлары күрсәтелә)

Бирелгән белешмәләрнең дөреслеге, шулай ук алар булган документларның

чынлыгы өчен җаваплы булам

____________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүче, ышанычлы зат яки законлы вәкил имзасы)

Мәгълүмат алу, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында мәгълүмат алуга риза:

әлеге адрес буенча язмача формада

әлеге телефонга смс-хәбәр итеп ____________________________

(телефон номеры)

электрон документ формасында

әлеге электрон почта адресы буенча ____________________________

(электрон почта адресы)

«Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша

____________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүче, ышанычлы зат яки законлы вәкил имзасы)

Бала өчен айлык пособиене яңа срокка автомат режимда билгеләү белән килешәм.

Гариза һәм документлар кабул ителде

________ _________ __________________________

(дата, белгечнең имзасы, тулы имзасы)

____________________________________________________________

Аеру линиясе

Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү номеры __________________

Документлар саны ___ берәмлек, ___ биттә

Документларны кабул итте

____________ __________ _______________________ _______________

(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)»;

Регламентка 5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

форма

РМЯҮ (КТ) бүлекчәсе N _____

кая ______________________________
муниципаль районында (шәһәрдә)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин, ____________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)
яши торган адрес ________________________________________________________
________________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)
________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ аталышы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы,
________________________________________________________________________,
документны биргән орган атамасы)
техник хатаны төзәтүне сорыйм ___________________________________________,
________________________________________________________________________,
жибәрелгән (кирәклесе астына сызарга):
дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында
________________ №_______________ карарда.
(карар датасы) (карар номеры)
балага айлык пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында
____________№____________ карарда.
(карар датасы) (карар номеры)

Үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны алуга риза:
________________________________________________________________________.
(язмача, телефон буенча, смс-хәбәр белән, электрон почта аша, ТР Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинет аша)

«__» ____________ 20__ ел. ________________________ ____________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)»;

Регламентка түбәндәге эчтәлекле 6 нчы кушымта өстәргә:

«Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта форма

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ бүлекчәсе
_______________________________________________
(муниципаль районында (шәһәр округында)

Бала өчен айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар

№___________ «__» _____________

Мөрәҗәгать итүченең ФИА ___________________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы ________________________________________________

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булу сәбәпле, айлык пособие түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатырга, ләкин дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көннән дә артыграк чорга түгел.

Бүлек җитәкчесе _____________ _________________
(Ф.И.А.) имза
мөһер урыны

Бүлек белгече _________________ __________________
(Ф.И.А.) имза
Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы:
Язмача ____________________________________________________
почта адресы буенча
sms-хәбәр итеп ____________________________________________
телефон номеры
электрон почта буенча _____________________________________
электрон почта адресы

Бүлек белгече _________________________ __________________
(Ф.И.А.) имза

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ бүлекчәсе
_________________________________________
(муниципаль районында (шәһәр округында)

Бала өчен айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту турында карар

№___________ «__» _____________

Мөрәҗәгать итүченең ФИА ___________________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы ________________________________________________

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычларны җайга салу белән бәйле рәвештә, балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте «__» ________ күрсәтүне яңадан торгызырга.

Бүлек җитәкчесе __________________ _________________
(Ф.И.А.) имза

мөһер урыны

Бүлек белгече ________________________ ___________________
(Ф.И.А.) имза

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы:

Язмача ____________________________________________________
почта адресы буенча

sms-хәбәр итеп ________________________
телефон номеры

электрон почта буенча _________________________________
электрон почта адресы

Бүлек белгече ___________________ ___________________
(Ф.И.А.) имза».